СОВЕТ НУРИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НӨНӘГӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ
«12»ноябрь 2021 ел

КАРАР
№38

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Нөнәгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 елешенең 20 пункты һәм «авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү вәкаләтләрен тапшыру турында» Балтач район Советының 8.11.2021 елдагы 84 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы “Нөнәгәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Советы карар итә:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Советының 31.05.2013 ел, № 78 «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Нөнәгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен раслау турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Ненәгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм тезү Кагыйдәләре» нә (2016 елның 13 декабрендәге 40 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 35.1 статьяда Ж-1 өлешендә Шәхси торак йортлар төзү зонасы авыл җирлекләрендә гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең минималь күләмен билгеләргә:

шәхси торак төзелеше ечен – 0,10 га мәйданда;
шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен – 0,10 га кадәр мәйданда;
бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек ечен-0,15 гектарга кадәр

1.2. Җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының иң чик минималь параметрлары таблицасындагы 35.1 статьяның Ж-1 зонасында «Аерым торучы индивидуаль торак йорт», «Блокланган торак йортта бер гаиләгә торак берәмлек» баганаларында 600 «санын» 1000 «санына алмаштырырга.

1.3. 35.2 статьяның Шартлы рәвештә рехсәт ителгән куллану терләре өлешендә авыл җирлекләрендә гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең минималь күләмен билгеләргә:

шәхси торак тезелеше ечен – 0,10 га мәйданда;
шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен – 0,10 га кадәр мәйданда;
бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек өчен-0,15 гектарга кадәр –

1.4. 35.1. статья. Шәһәр төзелешә регламентлары. Торак зоналар. II Глава 3 пунктка

түбәндәге эчтәлекле өстәргә:

«3. Җир кишәрлекләренең чик күләме:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен " рөхсәт ителгән җир кишәрлекләренең минималь күләме-1 000 кв. м.

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен " рөхсәт ителгән җир кишәрлекләренең максималь күләме -2 500 кв. м.»

2. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://pravo.tatarstan.ru/

3. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен ТР Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлегенең төзекләндерү, төзелеш, хокукларын яклау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе –
Нөнәгәр авыл җирлеге башлыгы: А. З. Әхмәтханов